**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КУТЛУ-БУКАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422665, с. Кутлу-Букаш,
ул. Советская, дом 32

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОТЛЫ БӨКӘШ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422665, Котлы Бөкәш авылы,
Советская урамы, 32 нче йорт,

Тел.: (84361) 31642, факс: (84361) 31642, e-mail:Kbuk.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.05.2019 Котлы Бөкәш авылы № 18

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Котлы Бөкәш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм “Җирләү һәм мәет кую эше турында” 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 маддәсендәге 3 пунктын, 12 маддәсендәге 3 пунктын үтәү йөзеннән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "2019 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында" 2019 елның 24 гыйнварындагы 32 номерлы карарына, “Татарстан Республикасында “Җирләү һәм мәет кую эше турында” Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында” 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 3 пунктына таянып КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Котлы Бөкәш авыл җирлегендә мәет кую буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1,2 кушымталар нигезендә 5946,47 сум күләмендә билгеләргә һәм 2019 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә,

2. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә һәм 2019 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең Котлы Бөкәш авылы, Совет урамы, 32 йорт, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Тәберде Чаллысы авылы, Совет урамы, 34 йорт, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Мәмле Казак Чаллысы авылы, Үзәк урам, 29 йортадреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Котлы Бөкәш авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Нәҗипов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2019 елның 7 маендагы
18 номерлы карарына
кушымта №1

**Татарстан Республикасы**
**Балык Бистәсе муниципаль районының Котлы Бөкәш авыл җирлегендә**
**2019 елның 1 февраленнән мәет кую буенча хезмәтләрнең**
**гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган**
**хезмәтләрнең бәясе**

| Хезмәтләрнең исеме | Хезмәтләрнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 1697 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (мәетен) зиратка (крематорийга) күчерү (илтү) | 929 |
| 4. Җирләү (мәетне яндыру, соңыннан көле салынган урнаны бирү белән) | 3320,47 |
| Барлыгы: | 5946,47 |

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2019 елның 7 маендагы
18 номерлы карарына
кушымта №2

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегендә ире (хатыны), якын туганнары, башка туганнары яисә мәрхүмнең законлы вәкиле булмаганда яки алар тарафыннан җирләүне гамәлгә ашыру мөмкин булмаганда яисә җирләү бурычын үз өстенә ала торган бүтән зат булмаганда, мәет кую буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча түләүсез нигездә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе**

| Хезмәтләрнең исеме | Хезмәтләрнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 468 |
| 3. Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 1229 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (мәетен) зиратка алып бару (илтү) | 929 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3320,47 |
| Барлыгы | 5946,47 |